| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БУРУНДУКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БОРЫНДЫК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«08»май,2024 ел Борындык авылы №78

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексынаһәм Россия Федерациясенеңаерым закон актларынаүзгәрешләркертүтурында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 октябрендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.9 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 абзац өстәргә:

««Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи, аларга федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) капитал салуларны финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булып тора.».

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http:/burunduk-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Борындык авыл җирлеге Башлыгы А.Р.Гайнетдинов